КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 октябрь г.Казань № 954

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 21 май, 413 нче, 2020 ел, 01 сентябрь, 772 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VI бүлекнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле $3.2^1$ пунктча өстәргә:

«$3.2^1$. Казан шәһәренең «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» полилингваль комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесендә белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр атнага (елга) педагогик эш сәгатьләре нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләр өчен хезмәт хакы ставкасы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sop_{pb}} = (O_b \times \frac{H_{f_{pb}} \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P) \times D_{sop_{pb}},$$

монда:

$B_{sop_{pb}}$ – «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» полилингваль комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесендә белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләү;

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_{f_{pb}}$ – предметларын инглиз яки татар телләрендә укыту сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ – гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең факттагы саны;

$H_N$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәрләренең хезмәт хакының әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P – педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаган күләмдә билгеләнә торган китап басу продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация;

$D_{sop_{pb}}$ – Казан шәһәренең «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» полилингваль комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесендә белем бирү программасы спецификасы өчен өстәмә күләме, ул 31 нче таблицада китерелгән.»;

3 нче таблицадан соң түбәндәге эчтәлекле $3^1$ нче таблица өстәргә:

«$3^1$ нче таблица

Казан шәһәренең «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» полилингваль комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесендә белем бирү программасы спецификасына өстәмә түләүләр күләме

| Т/с | Белем бирү программасы спецификасына өстәмә билгеләү нигезе | Белем бирү программасы спецификасы өчен өстәмәләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| | | һөнәри-квалификация төркеменең исеме | квалификация дәрәҗәсе | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Гомуми белем бирү оешмаларында предметларны инглиз телендә укыту | педагогик хезмәткәрләрнең вазыйфалары | дүртенче | 70,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | (полилингваль укыту программасы) | | | |
| 2. | Гомуми белем бирү оешмаларында предметларны татар телендә укыту (билингваль укыту программасы) | педагогик хезмәткәрләрнең вазыйфалары | дүртенче | 30,0». |

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин